**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2022 елның 12 августы №95

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының аерым норматив-хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләп, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының мәгълүматларын һәм норматив-хокукый актларын актуальләштерү максатыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын танырга:

- 2007 елның 8 февралендәге «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыелышларын һәм конференцияләрен билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 59 номерлы карары;
- 2011 елның 15 августындагы «Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль мөлкәтне аукционда сату тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 43 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**